**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАКТАЛАЧЫК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

423751, Такталачык авылы,
Г.Авзал ур.,48 нче йорт.
Тел/факс 3-44-57
e-mail : tak-akt@yandex.ru

**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН СОВЕТ ТАКТАЛАЧУКСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423751, с.Такталачук ул.Г.Авзал, дом 48.
Тел/факс 3-44-57.
e-mail : tak-akt@yandex.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**от «20»декабрь 2024ел.** **№26**

Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының 07.09.2017 ел, № 21 "Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында Нигезләмәне раслау хакында" карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану турында» 08.08.2024 ел, № 232-ФЗ Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Такталачык авыл җирлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының Такталачык авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының 07.09.2017 ел № 21 карары белән расланган Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Такталачык авыл җирлеге Советының 25.06.2018 № 15, 13.09.2018 № 23, 15.02.2019 № 3, 23.09.2019 № 27, 22.01.2020 №3, 12.10.2020 №21, 18.01.2021 №2, 14.07.2021 № 15, 26.06.2023 №6, 13.07.2023 № 8, 05.04.2024 № 3, 21.11.2024 №18 карарлары белән үзгәртелгән) түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) **1 бүлекнең 1.3 пунктында** «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе рәисе " сүзләрен төшереп калдырырга.;

2) **2 бүлекнең 2.2 пунктында** «, муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре» сүзләрен төшереп калдырырга.

3) **5 бүлекнең 5.1 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә::

«5.1. Муниципаль хезмәт вазыйфасы - җирле үзидарә органының яисә муниципаль вазыйфаны биләүче затның вәкаләтләрен үтәүне тәэмин итү буенча билгеләнгән бурычлар даирәсе булган муниципаль берәмлек уставы нигезендә төзелә торган җирле үзидарә органындагы вазыйфа.»;

4) **10 бүлек 10.1 пунктының 5 пунктчасында** «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә» сүзләрен төшереп калдырырга.;

5) **15 бүлекнең 15.2 пунктын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«15.2. Җирле үзидарә органы ябылуга йә җирле үзидарә органы хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә муниципаль хезмәткәр белән хезмәт шартнамәсен өзгәндә, муниципаль хезмәткәргә, оешма ябылуга йә оешма хезмәткәрләре штаты кыскартылуга бәйле рәвештә хезмәткәрләр эштән азат ителгән очракта, хезмәт законнарында билгеләнгән гарантияләр бирелә.»;

б) **19 бүлектә:**

**19.2 пунктта** «, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе» сүзләрен төшереп калдырырга.;

**пункт 19.3** изложить в следующей редакции:

19.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«19.3. Муниципаль хезмәткәр муниципаль хезмәт вазыйфасын биләгән җирле үзидарә органы бетерелгәндә, аның шәхси эше саклауга җирле үзидарә органына яисә аның хокукый варисына тапшырыла.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Актаныш муниципаль районы
Такталачык авыл Җирлеге Советы
белән рәислек итүче Р.Ф.Миннеханов